ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 97-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, И.И. Сәлахов, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 97-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 413-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов,
И.И. Сәлахов,
М.Х. Сәлахов,
И.В. Терентьева
тарафыннан кертелә

**«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш); 2020, №87 (I өлеш); 2022, № 49 (, өлешI); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 пунктында «Федераль закондагы» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 12 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Фән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте түбәндәге принциплардан чыгып гамәлгә ашырыла:
а) фәнне дәүләтнең җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсен билгели торган социаль әһәмиятле тармак дип тану;
б) фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләрен сайлаганда һәм конкурс нигезендә тормышка ашырыла торган фәнни-техник программаларга һәм проектларга экспертиза ясаганда һәркем өчен ачык булу һәм җәмәгать фикер алышуларының төрле рәвешләреннән файдалану;
в) фундаменталь фәнни тикшеренүләрне өстенлекле үстерүнең гарантияләнүе;
г) югары белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең һәм белем алучыларының фәнни тикшеренүләрдә һәм эксперименталь уйлап табуларда катнашуының төрле рәвешләре нигезендә югары белем бирү мәгариф оешмаларында лабораторияләр, фәнни оешмалар базасында кафедралар төзү юлы белән фән һәм мәгариф интеграциясе;
д) фән һәм техника өлкәсендә конкуренциягә һәм эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү;

е) фәнни-технологик үсешнең өстенлекле юнәлешләрендә ресурсларны концентрацияләү;

ж) фәнни, фәнни-техник, инновацион эшчәнлекне икътисадый һәм башка ташламалар системасы аша кызыксындыру;

з) фәнни, фәнни-техник, инновацион эшчәнлекне дәүләт фәнни үзәкләре системасын һәм башка структураларны төзү юлы белән үстерү;

и) тигез хокуклы һәм үзара файдалы нигездә Татарстан Республикасының халыкара фәнни һәм фәнни-техник хезмәттәшлеген үстерү;

к) Федераль закон нигезендә башка принциплардан.».

3) 13 статьяның 3 пунктында «фән һәм техника үсеше» сүзләрен «фәнни-технологик үсеш» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына АҢЛАТМА**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

2025 елның 24 июнендә үз көченә кергән «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе фәнни шәһәре статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 24 июнендәге 167-ФЗ номерлы Федераль законда дәүләт фәнни-техник сәясәтенең илне фәнни-технологик үстерүгә идарә итүнең тулаем механизмын булдыруга юнәлтелгән төп принциплары төгәлләштерелә, терминология бердәйләштерелә.

Моңа бәйле рәвештә «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законына республика законындагы терминологияне федераль законга туры китерүгә юнәлтелгән үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.